КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 гыйнвар г.Казань № 27

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 16 март, 228 нче карары белән расланган Эшсез гражданнарга, аларны һөнәри белем алуга һәм өстәмә һөнәри белем алуга башка җирлеккә җибәрүгә бәйле рәвештә, финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эшсез гражданнарга, аларны һөнәри белем алуга һәм өстәмә һөнәри белем алуга башка җирлеккә җибәрүгә бәйле рәвештә, финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 ел, 16 март, 228 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 2 февраль, 51 нче; 2017 ел, 6 декабрь, 938 нче; 2022 ел, 13 август, 808 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эшсез гражданнарга, аларны һөнәри белем алуга һәм өстәмә һөнәри белем алуга башка җирлеккә җибәрүгә бәйле рәвештә, финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләренә, 1 пунктның икенче абзацындагы «Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин